**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 14 декабрь № 946

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 23 ноябрь, 961 нче; 2012 ел, 15 май, 378 нче; 2014 ел, 11 июнь, 398 нче; 2014 ел, 27 ноябрь, 920 нче; 2015 ел, 17 апрель, 259 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 нче пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

«Административ регламентлар башкарма хакимият органнары тарафыннан, шул исәптән федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән

йөкләнгән аерым вәкаләтләрне башкарганда, дәүләт хезмәтен күрсәтү вәкаләтләре барлыкка килгән көннән соң 60 календарь көннән артмаган вакыт эчендә эшләнә һәм раслана;

икенче абзацка «дәүләт хезмәтен күрсәтү вәкаләтләре барлыкка килгән көннән соң 60 календарь көннән артмаган вакыт эчендә.» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацны өченче абзац дип санарга;

1.8 нче пунктның беренче абзацын төшереп калдырырга;

2.4 нче пунктның «о» пунктчасында «гариза бирүчеләр кабул итү урынына, » сүзләреннән соң «шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен әлеге объектлардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\946.doc